Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Нефтебаза поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Нефтебаза поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 5 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

«- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү»;

«- торак пункт территориясен төзекләндерү».

2) 1 пунктның икенче, дуртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 23 ноябрендәге 6 номерлы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Нефтебаза поселогы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

«- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү»;

«- торак пункт территориясен төзекләндерү».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева